СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОМОДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03 2020 с. Ромодан № 108

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Ромодан авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә 2015 елның 26 гыйнварындагы 76а номерлы, түбәндәге эчтәлекле:
- 13 маддәнең 16 пунктында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 30 маддәнең 2 пунктындагы 2 абзасында «кассадагы» сүзен «казначылыктагы» сүзенә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Ромодан авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.А. Чекалина**